Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«17» февраль 2021 ел. № 3

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге Башкарма комитетының
2020 ел, 04 февралендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 1 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның I яртыеллыгы өчен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджет үтәлеше нәтиҗәләре буенча финанс, казна һәм салым органнарының республика киңәшмәсе Беркетмәсенең 12 нче пунктын һәм 08.08.2020 елдагы ПР-167 номерлы Беркетмәсе нигезендә, 2020 ел ахырына кадәр финанс, казна һәм салым органнары бурычларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов вәкиллеге астында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 10 нчы пунктча белән тулыландырырга:

- “салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пеня, штрафлар, процентлар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнарына тәңгәл рәвештә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларның булмавын раслаучы салым органы белешмәсе”.

2.Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Башлык Ф.М. Мәүлин